**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БИЛЯР-ОЗЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**БИЛӘРКҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Biләркүл ав. **КАРАР**

«31» гыйнвар 2024 ел № 2

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биләркүл авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән Исемлеге бәясенең чик күләмен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «2023 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2024 елның 23 гыйнварындагы 46 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә Нурлат муниципаль районы Биләркүл авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Нурлат муниципаль районының Биләркүл авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1нче һәм 2нче кушымта нигезендә 8370,20 сум (сигез мең өч йөз җитмеш сум 20 тиен) күләмендә билгеләргә һәм 2024 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Нурлат муниципаль районы Биләркүл авыл җирлеге Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районы Биләркүл авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2023 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 01 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Биләркүл авыл җирлеге территориясендә мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче В.С.Оренбургов

Нурлат муниципаль районы Биләркүл авыл җирлеге Башкарма комитетының 2024 елның 31 гыйнварындагы 2 номерлы карарына 1нче кушымта

2024 елның 1 февраленнән ТР Нурлат муниципаль районы Биләркүл авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе

| № | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе |
|---|---|---|
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2 | Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны китереп бирү | 2792.40 |
| 3 | Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 1611.00 |
| 4 | Җирләү хезмәте (кабер казу һәм җирләү ) | 3966,80 |
|  | Барлыгы | 8 370,20 |

Нурлат муниципаль районы Биләркүл авыл җирлеге Башкарма комитетының 2024 елның 31 гыйнварындагы 2 номерлы карарына 2нче кушымта

2024 елның 1 февраленнән ТР Нурлат муниципаль районы Биләркүл авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе

| № | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе |
|---|---|---|
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2 | Мәетне кәфенләү (төрү) | 1288.80 |
| 3 | Җирләү өчен кирәкле әйберләрне бирү һәм китерү | 1503,60 |
| 4 | Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 1611,00 |
| 5 | Җирләү хезмәте (кабер казу һәм җирләү ) | 3966,80 |
| | Барлыгы | 8 370,20 |